# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Владимир торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 6 «25» октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Владимир торак пунктында 2024 елның «25» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Владимир торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, МХОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары сатып алу, урнаштыру)ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан тигезләү һәм чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 175 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 109 кеше, 63 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 109 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Владимир торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Владимир торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Владимир торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, МХОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары сатып алу, урнаштыру)ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан тигезләү һәм чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

3. Әлеге карарны Усали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе А.И.Зиатдинов